**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-985 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1090 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-915 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-370 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 июлендәге ПУ-396 номерлы, 2020 елның 18 апрелендәге ПУ-240 номерлы, 2020 елның 12 августындагы ПУ-482 номерлы, 2021 елның 5 октябрендәге ПУ-792 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 апрелендәге 234 номерлы, 2023 елның 1 сентябрендәге 612 номерлы һәм 2023 елның 24 ноябрендәге 808 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Р.И. Заһидуллинны, Е.Н. Ивановны, А.М. Фроловны чыгарырга;

б) Совет составына Таҗетдинов Айрат Бәшир улын – Федераль ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча) кертергә;

в) Совет әгъзасы Г.Р. Фәйзетдинованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесе».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 05 апрель
№ 267